СОВЕТ
БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ УРСАК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 26 гыйнвареОлы Урсакав. № 23

Татарстан РеспубликасыКайбычмуниципаль районы Олы Урсак авылҗирлегененгомумифайдаланудагыҗирлеәһәмияттәге автомобиль юлларыннанфайдаланучыларнымәгълүматитәэминитүхакынданигезләмәнерасла утурында

«Россия Федерациясендәҗирлеүзидарәнеоештыруныңгомумипринципларытурында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль юлларыһәмюлэшчәнлегетурындаһәм Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүтурында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Юл хәрәкәтеиминлегетурында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлыФедеральзаконнарһәм җирлеәһәмияттәге автомобиль юлларыннанфайдаланучыларнымәгълүматитәэминитү, автомобиль юлларыннанфайдаланучыларгакүрсәтеләторганхезмәтләрнеңсыйфатынарттырумак сатларында,Татарстан РеспубликасыКайбычмуниципаль районы Олы Урсак авылҗирлегеСоветыКАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан РеспубликасыКайбычмуниципаль районы Олы Урсак авылҗирлегененгомумифайдаланудагыҗирлеәһәмияттәге автомобиль юлларыннанфайдаланучыларнымәгълүматитәэминитүхакынданигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан РеспубликасыКайбычмуниципаль районы Олы Урсак авылҗирлегенен http://brusakov-kaybici.tatarstan.ruвеб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

Совет Рәисе,
Кайбычмуниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегеБашлыгы Г.А.Зиннәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбычмуниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге Советының
2022е. «26»гыйнвар23 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү турында

## НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларның автомобиль юллары, аларның торышы, эчтәлеге һәм ремонты турында мәгълүматны файдалана алуын тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

2. Мәгълүмат белән тәэмин итүнең төп принциплары түбәндәгеләр:

мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

мәгълүматның дөреслеге һәм аны вакытында тапшырылуы;

мәгълүмат эзләү, алу, тапшыру һәм тарату иреге.

3. Мәгълүмат белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга түбәндәге мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирү тәэмин ителә:

4.1. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары маршрутлары турында.

4.2. Тиешле участокларда юл хәрәкәтенең куркынычсыз шартлары турында.

4.3.Автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату шартлары һәм сроклары һәм аларны әйләнеп узу мөмкинлегеннән файдалану турында.

4.4. Транспорт чараларының хәрәкәт тизлеге турында.

4.5. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлыннан яисә мондый автомобиль юлы участогыннан түләүле нигездә файдалану турында һәм алар буенча транспорт чаралары йөрү бәясе турында, алар буенча күрсәтелә торган хезмәтләр турында, аларны түләү тәртибе, рәвешләре һәм системасы турында, мондый автомобиль юлы яисә шундый участок буенча транспорт чаралары йөрү бәясенә керә торган хезмәтләр исемлеге турында, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлы буенча транспорт чараларына альтернатив түләүсез йөрү мөмкинлеге турында карар кабул итү хакында.

4.6. Бер күчәргә исәпләгәндә мөмкин булган йөкләнеш турында.

4.7.Юлны реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау фактлары һәм сроклары турында һәм кирәкле очракларда әйләнеп узуның мөмкин булган юллары турында.

5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучылар түбәндәгеләргә хокуклы:

5.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында дөрес мәгълүмат алырга.

5.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында мәгълүматтан файдалану хокукын боза торган актларына һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге түбәндәге ысуллар белән тәэмин ителә:

6.1. Мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында бастырып чыгару.

6.2. Мәгълүматны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру.

6.3. Мәгълүматны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының гомуми файдаланудагы бүленгән полосаларында һәм юл буе полосаларында, биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның һәм башка техник чараларының конструктив элементларында, шулай ук җәмәгать транспорты хәрәкәте тукталышы пунктларында урнашкан һәм тотрыклы территориаль урнашуның мәгълүмат такталарында, стендларында, билгеләрендә һәм башка техник чараларында мәгълүмат урнаштыру.